СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

28 август, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№96(8108)

Бәясе билгеләнгәнчә

Ашлык - дәүләткә!

## Тагын дүрт хуҗалык

Район хуҗалыкларыннан дәүләткә ашлык сату дәвам итә. 27 августка тагын дүрт хуҗалык - шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгы, «Әлмәт» крестьян кооперативлары берлеге һәм «Нурлат агрофирмасы составындагы «1нче Май» һәм «Якты Күл» хуҗалыклары ашлык сату буенча 1997 елга дәүләт заказын тутырдылар.

Район хакимияте, халык депутатларының район Советы президиумы дәүләт алдындагы олы бурычларын вакытыннан алда намус белән үтәгән әлеге хуҗалыклар игенчеләрен кырларында мул иген уңышы үстереп алып, аны хәзерләү заданиесен алдынгылар рәтендә тутырулары белән кайнар котлыйлар, аларга нык сәламәтлек, гаилә бәхете, урып - җыюны үзвакытында төгәлләү, яңа уңышка ныклы нигез салып кую эшендә зур уңышлар телиләр һәм ашлык ресурсларына булган ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерәчәкләренә ышаныч белдерәләр.

## Вакытында урнаштыру шарт

(Урып - җыюның үзәк штабында)

**Район хуҗалыкларында быел моңарчы күрелмәгән мул иген уңышы үстерелүе ашлыкны көннәр коры торганда ышанычлы саклауга урнаштырып калу буенча аеруча киеренке эшләү зарурлыгын алга куйды.**

**Шуны истә тотып, үзәк штаб ашлыкны дәүләт амбарларына ташу буенча**

**удар үнкөнлек**

**игълан итте.** Бу чорда ашлык ташуга катнаштыру мөмкин булган барлык автотранспорт та шушы максатка файдаланылырга тиеш. Шәхси йөк транспорты булган кешеләр дә бу җаваплы эштән читтә калмаслар һәм тормыш тоткасы булган икмәк язмышы өчен көрәшкә үз өлешләрен кертерләр дип өметләнәбез.

Штаб утырышында урып - җыюны оешкан төстә төгәлләүгә кагылышлы башка мөһим мәсьәләләр дә каралды. Аерым алганда, кырдагы бер генә комбайн да, ашлык ташудагы бер генә автомашина да ягулык яки майлау материалы юклыктан басып тормасын өчен кискен чаралар күрерлергә тиешлеге ассызыкланды. Район хакимияте бу мәсьәләне көндәлек игътибар үзәгендә тота һәм ул юнәлештә эшлекле чаралар күрә килә. Бер үк вакытта җитәкчелек авыл хезмәтчәннәренә эш хакы бурычларын капლау мөмкинлекләрен табу буенча да чаралар күрә . Шулай булгач, ашлык язмышы хәл кылынган бу җаваплы көннәрдә авылдагы һәркемнең уртак эштә бар көченә катнашуы, икенче төрле әйтсәк, бу киеренке чорда вакыт белән исәпләшеп тормыйча тырышуы да зарур дип карала. Кызганычка каршы, күп кенә урыннарда урып - җыю агрегатларының эшкә соң керешеп, иртә туктавы гадәти хәл әле. Югыйсә бит иртәнге чык комбайннарга эшкә бик иртә тотынырга ирек бирмәсә дә, башка кыр эшләренә, аерым алганда салам җыю, көзге чәчүгә һич тә комачауламый бит. Ә инде түнгә сөрү агрегатларын фәкать ике сменада эшләтү турында әйткән дә юк. Ул мөһим эшнең темпын да арттыру, сыйфатын да яхшырту зарур әле. Бигрәк тә соңгысы һәркайда да тиешле таләпләргә җавап бирми әле һәм күптән түгел генә сабанчыларның район конкурсында күрсәтелгән эш үрнәкләре янында бу һич тә күңелле хәл түгел.

Штаб утырышында башка мөһим мәсьәләләр дә кузгатылды.

## Президент котлавы

**27 августта район хакимияте Ф.С.Сибагатуллин исеменә Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев кул куйган хөкүмәт телеграммасы алынды. Анда мондый юллар бар:**

***«Хөрмәтле Октябрь районы хезмәтчәннәре!***

**Сезне республикада беренчеләрдән булып дәүләткә ашлык сату буенча килешү йөкләмәсен үтәп чыгуыгыз белән чын күңелдән котлыйбыз. Игенчеләрнең фидакарь хезмәте, югары технологияләр һәм зур оештыру эше нәтиҗәсе буларак район кырларында бөртеклеләрдән моңарчы күрелмәгән зур - гектарыннан 40 центнерга якын уңыш үстерелде һәм бу кыска гына вакыт эчендә республиканың дәүләт амбарларына 30 мең тоннадан күбрәк яхшы сыйфатлы ашлык, шул исәптән 18 мең тонна ашамлык бодае озатырга мөмкинлек бирде. Татарстан Республикасы мөстәкыйльлегенең 7 нче еллыгы көненә хезмәт бүләгегез өчен сезгә зур рәхмәт.**

**Алга куелган максатка ирешүгә аеруча зур өлеш керткән «Кондырча» (Й.Г.Әхмәтсафин), «Татарстан» (Ф.М.Гыйльметдинов), Хафизов исемендәге (В.Ф.Булатов), «Заветы Ильича» (А.И.Баранов), Кузнецов исемендәге (Е.К.Савинов), «Тәрнәс» (Р.Г.Шәйдуллин), «Таң» (Ә.М.Шәрәфетдинов) крестьян хуҗалыклары ассоциацияләре коллективларына урып - җыюда югары күрсәткечләре өчен аеруча рәхмәтлебез.**

**Сезнең дәүләт амбарларына саклауга тагын 50 мең тонна ашлык салу турындагы тәкъдимегезне канәгатьләнү белән кабул иттек.**

**Сезгә ныклы сәламәтлек, бәхет һәм барлык эшләрегездә яңа уңышлар телибез.**

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.ШӘЙМИЕВ».**

## Алдынгылар үрнәк күрсәтә

Амбарларыбыз ашлык белән тула. Авыл хезмәтчәннәре августның урып - җыю көннәренең һәр сәгатен, һәр минутын файдаланып калырга тырышалар. Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин байтак кына урак батырына үзенең котлау хатын җибәрде. Менә аларның исемнәре:

**А.Н.Виноградов һәм А.П.Федоров (җыелма отряд).**

**А.С.Белогубов һәм В.М.Прохоров (җыелма отряд).**

**А.В.Тәмаев («Кондырча»КХАсы).**

**А.В.Родионов (Синдряков исемендәге КХА).**

**И.И.Мингалимов («Киекле» КХАсы).**

**Ф.Г.Әхмәтвәлиев («Рассвет» КХАсы).**

**Афәрин, игенчеләр!**

## Ял көннәре

Былгы Республика көненең ял көненә туры килүе календарьда кайбер үзгәрешләр китереп чыгарды. Шулай итеп, 30 һәм 31 август, 1 сентябрь ял көннәре дип игълан ителде. Әмма мәктәпләрдә «Белем көне» һәрвакыттагыча 1 сентябрьдә үткәрелә. Ул көнне эшләүчеләрнең чираттагы ялы бер көнгә озайтылачак.

Гөлүсә Нугаева

## ТОРМЫШ ЯМЕ

*Кайчан гына җәй иде дә*
*Кай вакытта көз җитте.*
*Тук башаклы игенкәйләр*
*Гәрәбә булып пеште.*

*Диңгез кебек киң кырларда*
*Йөзә кыр кораблары.*
*Көнне төнгә ялгап эшли*
*Җирнең газиз уллары.*

*Маңгай тире тамган җирнең*
*Сые гел мулдан була.*
*Икмәк белән бергә илгә*
*Шатлык һәм бәхет тула.*

*Эшләп ашау- гөрләп яшәү*
*Бу тормышның яме бит.*
*Халкыңның хезмәт җимешен*
*Татарстан, кабул ит.*

## Эшләренә сокланырлык

Камил Сәлахов белән Габделәхәт Гобәйдуллин - Муса Җәлил исемендәге КФХА ның тәҗрибәле механизаторлары. Алтын куллы osталар. Белмәгән, башкармаган эшләре юктыр аларның. Язгы кыр эшләре чорында икесен дә ДТ-75 тракторында күрсәң, көзен чөгендер казыту комбайннарында очратасың. Урак чорында Камил дә, Габделәхәт тә комбайн штурвалы артына баса. Кыр корабларының төрлесендә эшләделәр. Куәтле ДОН-1500 ләрне иярләвләренә дә күптән инде. Егетләр тырышып, булсынга эшлиләр. Комбайннары төзек. Эш күрсәткечләре дә әйбәт. Әле менә Камил ярдәмчесе Айрат Шәйхиев белән соңгы бер көндә турыдан-туры урып-суктырып 1050 центнер ашлык җыеп алды һәм смена нормасын 272 процентка үтәде. Шул кадәр ашлыкны ГАЗ-53 белән ташып өлгергән Камил Миннеголовның эшенә дә сокланырлык. Шул басуда «Нива» комбайнында эшләгән Марат Гатин белән булышчысы Шамил Мусин да ул көнне рекорд куйдылар - ике норма үтәделәр.



**Рәсемдә: Муса Җәлил исемендәге КФХА комбайнчылары Камил Сәлахов (сулдан икенче) һәм Габделәхәт Гобәйдуллин үзләренең ярдәмчеләре Сабир Мостафин һәм Чаллыдан кунакка кайткан А.Шәйхиев белән.**

**Ж. Шакиров тексты,**
**Н. Азизов фотосы.**

## КАЗАНДА БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАРА

### Рәссамнар күргәзмәсе

Татарстан Рәссамнар берлегенең күргәзмә залында, II Бөтендөнья татар конгрессына багышлап зур күргәзмә ачыла. Бирегә куелган барлык картиналарда татар халкының гореф - гадәтләре, язмышы һәм мәдәнияте чагыла. Тамашачылар игътибарына сәнгатьнең бөтен төрләрен эченә алган 200 картина тәкъдим ителә.


**(«Илһамият» газетасыннан)**

### Шамаил ясый торган урыс

Сәүдә - промышленность палатасында «Хәзерге шамаил сәнгате» дип исемләнгән күргәзмә эшли башлады. Ошбу вернисажның авторы - Казан рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм Россиянең халык рәссамы Владимир Попов.

«Үзе христиан кешесе, үзе изге шамаилләр остасы» дип олылыйлар аны. Күркәм хезмәтләреннән торган бу күргәзмәне оста II Бөтендөнья татар конгрессына багышлый.

**(«Шәһри Казан» газетасыннан)**



# «Төрнәс»тә - иң кызу чак

## «Кейс»ларга тынгы юк

Гаҗәеп матурлыкка ия булган бормалы - сырмалы бу кырларны «Төрнәс» КХАсында үзара «Дегетле» дип атыйлар. Хуҗалыкның үзәк бүлекчәсенә кергән бөртеклеләрнең «кисәкләре» шулар инде. Баш агроном Александр Титов нәкъ шул җирдә кара туфракның ят күзләр игътибарына ташланмый да торган көллегә күчә торган чиген күрсәтә: бу якта җир көл генә.

Ләкин быелгы кайгыртучанлыкны ул рәхәтләнеп кабул итә! Күпме минераль ашлама ала алды, шулкадәр кертелде, җир моңа рәхмәтле дә булды. Әнә алтынсу төстәге урылган кыр һәм көнбагыш зурлыгында вакланган арпа кыры күзләргә күркәм ничек!. Хәер,кайсына гаҗәпләнергә дә белмәссең: әллә биш чит ил «Кейс»ының 71 гектарны 3 сәгать эчендә ялап диярлек чыкканынамы (гадәти техника белән моңа шактый күбрәк вакыт таләп ителер иде, аннары саламы белән дә никадәр мәшәкатьләнәсе), әллә шул җирләрнең элек булмаганча уңыш бирүенәме - гектарыннан 42,5 центнер ашлык җыелды! Хәтта «кейс»ларга да кызу тоелды. Шул ук җыелма отрядның 7 КамАЗы комбайннар бункерыннан чыккан бөртекне ындыр табагына чак кына илтеп өлгерттеләр, әле ярый анысы якын. Ә анда эш барышы Сенькиннар гаиләсе - Ранас Владимирович, хатыны, улы, кызына йөкләнгән. Әйтерсең лә, гаилә подряды! Белгечләр бертавыштан, шөкер, ындыр табагы өчен башыбыз авыртмый, диләр. Сенькин бик ышанычлы, тырыш кеше. Чынлап та,бу бишесе гаҗәеп оста итеп, сабыр хәрәкәтләр белән, сирәк кенә «тартып алуларда» вакытны исәпләп кенә көн саен тау - тау ашлык күчерәләр. Шулай яктыдан караңгыга кадәр...

## Фоминнар, Рябовлар, Куликовлар...

Хуҗалыктагы механизаторлар корпусының зур булмаган исемлеген тагы берничә фамилия белән тулыландыру урынлы. Болар - Иван Казаков, аның улы Алексей, Сергей Казаков, Рафаэль Вахитов, Александр Куликов, Евгений Христофоров, Виктор Рябов, Валерий Дмитриев, Александр Степанов һәм башкалар. Алар һәммәсе дә быелгы урып - җыюда һәм көзге чәчүдә катнашалар. Хуҗалыкта үз көчләре белән «ДОН» һәм чаптыруга җайланган 5 «Нива»ны «аякка бастырып» кырга чыгардылар. «Төрнәс»тәге бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культураларның гомуми мәйданын 1750 гектар булуын исәпләгәндә бу техника башка хуҗалыкларныкыннан күп тә түгел. Шуңа карамастан, дустанә рухта, иң мөһиме - төгәл оешканлык һәм сыгылмалы тактика белән тәэмин ителгән урып - җыю кампаниясе үз җимешләрен бирә: бүгенге көнгә ашлык барлык мәйданның яртысыннан суктырылды. Ә бит бу хуҗалыкны да башкаларның тәңкәсенә тигән проблема, бигрәк тә бензин, ГСМ кытлыгы читләтеп үтми. Шулай да үз унмеңчеләре булыр, боерса! Шул исәптән бүген җиденче меңнәрен суктырып тәҗрибәле, күптәнге комбайнчы Александр Михайловичның эзенә басып килүче Фомин - Куликов яшьләр экипажы да үз йолдыз сәгатьләрен билгеләп үтәрләр әле. Бу ике данлыклы Рябовлар һәм Фоминнарның игенчеләр нәселләре «Төрнәс»тә дистәләгән еллар буена игенчелекнең нигезен тәшкил итәләр. ДОН комбайнчысы Евгений Фоминның әтисе Александр Андреевич озак вакытлар буе совхоз кырларын тракторлар, комбайннарда иңләде, хәзер үзәк ремонт остаханәсендә аккумуляторчы булып эшли, асылда остаханәнең тулаем электр хуҗалыгы өчен җавап бирә. Евгенийның бабасы Андрей Васильевичның комбайн «капитаны» күперчегеннән лаеклы ялга китүенә дә әле 10 гына ел. Ә ул үзе яшүсмерләрчә, «газета алдында» оялып, ярдәмчесе белән армиядән соң беренче тапкыр урakka чыгуын әйтә. Тик менә алтын башаклар алдында егетләр тыйнаклык саклап тормыйлар!

## Вакытында чәчсәң...

башак кына түгел, ә игенче тырышлыгына лаеклы икмәк җыеп алырсың. Бу, кем әйтмешли, без ачкан хакыйкать түгел. Төрнәслеләр дә уҗым чәчүне үз вакытыннан соңга калмас өчен күп көч куялар. Ул эш ике агрегаттагы - берсе үзәктә, икенчесе Төрнәс бүлекчәсендәге механизаторларга һәм чәчүчеләргә йөкләнгән һәм 50 процентка үтәлгән дә инде. Биредә, «Дегетле»дә уҗым арышын Марат Камалов җитәкчелегендәге ДТ - 75 экипажы алып бара. Аның тракторчылык стажы чорына карап аз түгел - 5 ел туры килә, агротехниканы әйбәт белүе, намуслы хезмәткәр булуы да күпне сөйли. Әнә трактор бригадасы бригадиры Виктор Васильевич Маркелов та раслый бу фикерне (ул әле генә кырда эш хакы исәбенә теләүчеләргә тәмәке таратты (аның хакында биредәгеләр аеруча моңсулык белән «күптән түгел март аена аванс бирделәр... диләр): «Егетләр куркып түгел намус белән эшлиләр». Чынлап та көн яктылыгында алар яхшы итеп әзерләнгән туфракның 40ар гектарына орлык салалар, бу нормадан күпкә артыграк. Ашыгу да тыела бит әле: төрле яклап чәчкәндә чәчү нормасын да, кертелгән ашламалар исәбен дә ныклы контрольдә тоту зарур. Ә җәй матур тәмамланганда, уҗымнар чыгышының сыйфатлылыгы турында борчылырга урын юк: бары тик элита - класслы, һәртөрле бәйләнчек инфекциягә каршы чаралар корылган орлык кына чәчелә.

## «Суданка» - сихри үлән

Байтак сыйфатлары белән хәйран калдыра ул. Беренчедән, тропик үлчәмнәрдәгедәй биеклеге, куелыгы, авырлыгы белән, икенчедән шундый ук уңыш күрсәткечләре (ышанып әйтүем түгел) беләндер, мөгаен, өченчедән аеруча кыйммәтле ягы дымга, туфракка, азоттан кала ашлама белән туендыруга талымсызлыгы белән дә гаҗәпләндерә. Тәрбия таләп итмәве тагын да ис китәрлек. Башка культуралар өчен зур куркыныч яный торган солыча, билчән кебек үләннәр дә судан үләне өчен «чүп кенә»: ул аларны үзе үстерми.

Менә шушы исеме географик чыгышын аңлата торган сихри үләнне «Төрнәс»нең «Дегетле»сендә күрергә насыйп булды. Беренче тапкыр аны былтыр чәчеп карыйлар. Бер өлеше иртә салына торган силоска китә, шунысын әйтергә кирәк, искиткеч сыйфатлы азык килеп чыга, хайваннар «кисәкләрен» дә калдырмыйча юк итәләр, ә калганы 11 гектар җирдән орлык булып өлгерә. Быел да ул 7 гектарда озын, нәзек сабагында зур яфраклары һәм тузган башы белән җилдә җилфердәп орлыкка әзерләнә. «Бу басудан 10 тонналап орлык алырга ниятлибез»- ди баш агроном һәм: «Бер җәйдә аз дигәндә өч тапкыр печән чабабыз биредән. Азык өчен 9 - 10 процент аксым тәшкил итүе белән кыйммәтле ул,- дип дәвам итә. - Эшкәртү технологиясе дә гади - сай культивация, чәчкәч һәм соңрак икенче тапкыр тырмалау. Безнең көлле туфракта ул орлыкка да иртә өлгерә. Менә шундый ул - сихри, башка культураларга охшамаган, кыргый судан үләне.

## Тук тамактан эш тә курка

«Шатлык- һәммәбезгә дә бер булса»... - дип җырлана җырда. Төрнәслеләр өчен дә шулай, түземсезлек белән көтелгән, оста игенчеләр буыннарының ифрат зур мәшәкатьләре белән ирешкән көн килде - җир моңарчы күрелмәгән уңыш бирде: бөртеклеләр һәр гектардан 38 центнердан да аз түгел (күбрәккә дә өмет бар), ә бөртекле - кузаклы культуралар - 27 - 28әр центнер чыкты. Дәүләткә бер мең тоннадан артык яхшы сыйфатлы икмәк озатылды һәм бу әле башы гына.

ЗИЛ шоферы Иван Васильевич Беловның эчкерсез әйтүенчә: «Менә шуңардан тормыш та яхшырып китсә иде ул...»


Әлегә урак үзенекен ала, кем әйтмешли халыкның сулыш алырга да вакыты юк. Шул чакта көнкүреш турында төгәлрәге аннан башка бернинди энтузиазмга да юл куелмый торган мөһим мәсьәләне кайгырту - тукландыру зур ярдәм булып тора. Механизаторлар оста куллы кухня хезмәткәрләре аш пешерүче Исламия Әхмәдиева, аның ярдәмчеләре Валентина Сиплатова, Зоя Макарова турында рәхмәт хисләре белән искә алалар. Тынгысыз хатын - кызлар игенчеләрне «буразнада» төшке аш белән генә түгел, кичкесе (ул биредә бушлай) белән дә сыйлыйлар, пилмән, сумсалар пешереп куандыралар. Тәмле ашагач, эш тә гөрләп бара. Ә бу хакта механизаторлар беренче куллардан белеп торалар: Тамара Петровна Варламова җитәкчелегендәге экономик служба урып - җыюның барышы хакында хәбәр итми калмый. Соңгысы - уңайга гына. Алга таба да шулай булсын иде.

Д.ТӘМАЕВА.

# Булган малга сан юк

Хәзер элеваторда эшнең иң киеренке чагы. Предприятиенең үзәк лабораториясе янына һәр көнне яңа уңыш ашлыгын төягән өч йөзләп машина килеп туктый. Әмма алар биредә берсе дә озак тоткарланмый. Лабораториядә эшләүче кызларның җитезлегенә дә, түземлелегенә дә сокланырлык. Анализга орлык алгыч агрегатларның берсе бодай, икенчесе башка төрле культураларның үрнәкләрен бер - бер артлы биреп кенә торалар, ә кызлар аларның чүплелеген бер күз салу, дымлылыгын учка алу белән чамалап, кайсы машинаны кайсы участокка озатырга икәнлеген билгелиләр. Дөрес, соңынннан дымлылыкны да махсус аппарат ярдәмендә йөздән бер дәрәҗәгә кадәр билгелиләр, чүплелекне исә ашлык үрнәген бөртекләп аралап исәпләп чыгаралар. Шуңа күрә лаборатория кызларының эше никадәр киеренке булуын чамалавы кыен түгел. Әле эшнең иң мәшәкатьлесе һәм җаваплысы - бодайның җилемсәлелек дәрәҗәсен ачыклау. Күп өлешен кулдан башкара торган шушы эшне үтә дә сабырлык белән үтиләр кызлар. Кадерледән кадерлерәк икмәк язмышы өчен җаваплылыкның зур өлешен үз җилкәләренә алган коллективның үз вазифасына шундый мөнәсәбәте аңлашылада: кырларда авыл кешесе ел тәүлеге хезмәт куеп үстергән ашлыкның язмышы, бу очракта игенченең дәүләткә тапшырган ашлыгы нинди чуттан кабул ителәчәге, аның өчен күпме түләнәчәге нигездә шушы кызларга бәйле. Шуңа күрә дә хуҗалыкларның баш агрономнарына, җитәкчеләренә элеваторның үзәк лабораториясе белән ныклы һәм даими элемтәдә тору кирәклеге бәхәссез. Моны яхшы аңлаганнар биредә: әледән - әле күренгәләп китәләр. Әмма, кызганычка каршы, лаборатория ишегенең кайсы якка ачылуын да белмәгән агрономнар да бар әле. Андыйларның урында эшләре бик тыгыз булуга сылтаулары белән килешергә дә мөмкин булыр иде. Әмма бит элеватор белән язмача рәтле элемтә тотмаучылар да шактый. Сүз биргә озатыла торган ашлыкның, бигрәк тә бодайның озату документларының тиешенчә тутырылмавы турында. Мәгълүм булганча, район хуҗалыкларында бодайның берничә сорты игелә, ә накладнойларда бу хакта мәгълүмат юк диярлек. Бары тик теге яки бу культураны сортлы орлык буларак тапшырасы булганда гына аның сортын язып җибәрәләр. Ә калган бодайлар үрнәкләренең барысында да бер генә язу тора - «бодай». Шуңа күрә лабораториядә бодайның төп күрсәткече булган җилемсәлелегә дә гомуми төстә генә ачыклана. Ә бит кайсы бодайның сыйфаты ниндиерәк булуын анык белми торып аларның кайсысын киләсе елга орлыкка калдыру, кайсысын әйләнештән төшереп калдыру кирәкле-

# «Олыгайган дисәләр дә, картайган димәсеннәр»



Комбайны трапыннан җәһәт сикереп төште ул. Урта буйлы, нык гәүдәле. Сөрмә тарткандай кара керфекләренә яшеренгән зәңгәр күзләрендә чаткылар биешә.

- Безгә Илья Николаевич кирәк иде...

- Мин булам ул.

- Пенсионер Паруковны эзлибез без.

- Паруков алдыгызда. Мин ул пенсия алучы, ә үземне пенсионер санаган юк. Гомумән, бу сүзне бөтенләй яратмыйм...

Күп тә үтмәде, «пенсионерыбыз» «ДОН»ы белән алда калган теземен «йоттырды»да, янә безнең яныбызга килде. Йөзе тузанлы, күп нәрсә күргән кепкасы астыннан тырпаеп торучы чәчләренә салам кисәкләре шактый кунган булса да, күзләре шат, очкынлы иде. Илья Николаевичны. Йөзендә арыганлыгының ник бер әсәре булсын. Әйтерсең лә, иртәнге 4тән торып килмәгән комбайны янына, әйтерсең лә, ярты төнгәчә эшләми. Әйтерсең лә, яше дә җиденче дистәне вакламый.

- Картаерга ашыкмыйм. Эшләүдән тәм табам, җаныма да, тәнемә дә сихәт алам,- ди комбайнчы,- комбайнга да үзем сорап утырдым...

Ә эшли икән инде, бөтен җанын - тәнен биреп эшләргә күнеккән Паруков. Яшь чагында ничек спортка бирелеп, аңа озак еллар турылыклы калган иде, хәзер дә шулай... Заманында көчле велосипедчы даны бар иде аның. Татарстанның җыелма командасы составында ярышларга да йөрде. Шуларның берсендә егылып, җилкә башын сындырмаган булса, велосипед спортын бүгенгәчә ташламаган булыр иде, мөгаен. Аның каравы спортның «оеткысы» бөтен гомеренә җитте. Бер тапкыр да авырганы, больничный дигән кәгазьне үз күзе белән күргәне юк. Шифаханә юлын исә бөтенләй белмәгән. Йөзендә һәрчак елмаю балкый. Елмаеп җибәрсә, тип - тигез җепкә тезелгән күк энҗедәй ап - ак тешләре җемелдәшә. Баксаң, шушы яшенә җитеп бер тешен дә суыртмаган икән әле пенсионерыбыз. Күзе дә әйбәт күрә.

- Гел хезмәттә мин. Эш картайтмый кешене, ә менә хәмер, тәмәке «тетә» ир - атны. Беренчесе белән бераз дуслыгым булса да, икенчесе - авызыма алган нәрсә түгел.

Илья Николаевичның хезмәт биографиясе җиңел булмый. Әле үсмер малай килеш сугыш авырлыкларын татый, яшьли хезмәткә өйрәнә. Комбайнчы абыйлары, инде мәрхүм Василий һәм Петр янында ярдәмче дә булып йөри. Кыр корабына мәхәббәте дә шушы елларда кабына. Мөстәкыйль рәвештә комбайн штурвалы артына утырып эшләвенә дә шул сәбәпче була. Карусыз Петр производство ихтыяҗы буенча терлекчелектә, озак еллар бригадир булып эшләргә туры килсә дә, игеннәр өлгергән вакытта җаны кырга ашкынмаган җәе булмый. Ниһаять, 1981 нче ел урагында ул үзенә «Колос» комбайны алып, басуга чыга. Тырыша. Әмма «тәнәфес» үзенекен иткән булып чыга: кораб штурвалы «тыңламый», ургыч исә Илья теләгәнчә эшләми, өстәвенә ватылып та газаплый.

- Әһә, күнекмәм «бирешкән»,- дип уйлый механизатор,- димәк, алга таба комбайннан аерылмаска кирәк булыр...

Ир сүзендә тора. Икенче елгы уракта исә Илья үзен бөтен районга таныта: иң күп ашлыкны ул суктыра. Шуның өчен район фондыннан «Жигули» бүленә Паруковка.

Инде менә «ДОН»га утыруына да быел алтынчы ел. Хуҗасы кебек, танктай үкереп эшли аның корабы. Яхшы итеп төзәткәч, ватылып - нитеп тә азапламый. Әнә, быел җәй, мәктәптә хуҗалык мөдире булып эшләгән җиреннән директорның рөхсәтен алуга ук мастерскойга йөгерде бит. Яше олыгайса да, күңел картаймый: комбайн күрдеме күңеле ашкына башлый аның.

- Пенсияңне алып, өйдә генә утыр инде, карт җүләр,- дип карый хатыны Роза. Ә Илья исә аны ишетмәмешкә дә салыша: эш киемнәрен кия дә китә мастерскойга. Ә монда... май, солярка исе күңелгә шундый якын, ә тимер - томырларның әйтерсең лә җаны бар. Ә өе өчен күңеле тыныч аның: хатыны Роза, гаиләсе белән бергә төп йортта яшәүче улы Александр йорт тулы терлек, кош - кортны да, бакчаны да карыйлар. Илья Николаевич умарталарын гына бик ышандырып бетерми аларга: ярый ла быел үзе уракка төшкәнче күч аерып калдылар. Умарталарга мәхәббәте дә шушы җансыз комбайнга булганнан һич ким түгел. Югыйсә, Розасы теләсә нинди эшне кырып - себереп куя. Гомер буе эш белән мәшгуль булды ул да. Бергәләп, биш бала үстерделәр. Берсе генә дә укып, һөнәр алмыйча калмады. Ата - ана, туган йортлары - ышанычлы тыл алар өчен: юату, тынычлану, ярдәм алу урыны да ул.

- Олыгайган дисәләр дә, картайган димәсеннәр, алга таба да шулай эшләп яшәргә язсын иде,- диде безнең белән саубуллашканда Илья Николаевич.

Озак та үтмәде пенсионерыбызның «ДОН»ы теземнәрне «йота - йота» алга кузгалды. Әле генә зәңгәр күзләрендә очкыннар уйнатып, ап - ак тешләрен күрсәтеп елмайган абзыебызны танырлык түгел иде инде: карашы җитди, хәрәкәтләре ышанычлы. Әйе, икмәк язмышы җитди нәрсә шул. Ә Илья Николаевич галиҗәнаб икмәк язмышын хәл итүчеләрнең берсе бит. Әле ниндие!

**Р.ГИНЯЕВА.**

**Рәсемдә: Хафизов исемендәге КФХА комбайнчысы И.Паруков. Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Басылганга кире кайтып

**Газетада шәһәребезнең шикәрчеләр поселогында мәчет төзелешенең барышы турында берничә тапкыр язып чыктык инде. Төзелеш акрын бара дип, шәһәр промышленность предприятиеләре җитәкчеләрен, якташларыбызны, бөтен җәмәгатьчелекне бу-эштә ярдәм итәргә чакырып аваз салганыбыз булды. Бүген әлеге мәчет төзелеше ни хәлдә соң? Шул сорау безне янә әлеге мәсьәләгә әйләнеп кайтырга мәҗбүр итте.**

# Төзелеш ярдәмгә мохтаҗ.

Дөресен әйтим, әллә ни югары « үрләмәгән» мәчет. 1995 елда нигез салынган әлеге гыйбадәт йортының беренче катын төзүгә саллы ярдәмне РСУ күрсәткән, халыктан кергән акча исә икенче катны торгызуга бик ярап куйган. МСО, шикәр заводы, урман промышленносте хуҗалыгы коллективларының да мәчет картлары алдында йөзләре ак: көчләреннән килгәнчә ярдәм иттеләр алар төзелешкә. Картлар үзләре кордашлары-төзүче булып эшләп лаеклы ялга киткән Зөфәр Гыймаевка да бик рәхмәтлеләр. Быел язгы айларда элек үзе белән эшләгән егетләрне бер бригадага туплап, төзелеш эшен шактый алга җибәрә алган ул.

Шулай да мәчет быел сафка керер дигән өметне реаль дип булмый әле. Ни өчен дигәндә, бүген төзелештә үле тынлык. Югыйсә, Норлат җирле үзидарә советы карары белән төзелешне тәмамлау эше аерым предприятиеләргә беркетелгән. Әйтик, РСУ объектта сылау - буяу эшләрен башкарырга тиеш, НУРБга исә манара ясау кебек җаваплы эш йөкләнгән. Беренчесе әле бу эшкә керешмәгән, икенчесе исә манараның ике секциясен ясаган да, әзер материал юклыкны сылтау итеп, эшне ярты юлда туктаткан. Карар нигезендә башка эшләрне башкарырга тиеш тагын берничә оешма да төзелешкә үз өлешләрен кертергә ашыкмыйлар.

-Көзгә кадәр бинаның түбәсен булса да ябып калдырасы иде,- дип борчылалар мәчет картлары.Һәм, бу теләк урынлы да. Мәчет төзелеп бетсә, картлар да кемнеңдер фатирында түгел, ә үз мәчетләрендә гыйбадәт кыла алырлар иде.Халык та шуңа өметләнә. Шул көнне якынайту өчен хәләл сәдакалары белән дә өлеш кертергә тырышалар. Әнә, соңгы көннәрдә генә Сания Сөбханкулова 230, Гарифулла Вәлиуллин 150, Әсхәт Нәбиуллин,Тәлгать Газизов, Хәлил Хәйретдинов, Сәрхүлә Җамалиева шул изге эш өчен 100әр мең сум сәдака биргәннәр.

Быелның 14 маенда Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния Нәзарәтенең 217 нче карары нигезендә шикәрчеләр поселогындагы 1290 нчы мәхәлләсенә яңа имам-хатыйб итеп Йосыф Гали улы Зәйнетдинов билгеләнүе уңаеннан да төзелештә эшләр җанланыр һәм, ниһаять, әлегәчә үз гыйбадәт йортлары булмаган бу поселок та мәчетле булыр дигән өметтә яши картлар. Халык та шундый ышаныч белдерә.

**Р.МИНАПОВА**

---

ген ничек хәл кыласың ди. Күрәсең, хуҗалыкларда бары бер күрсәткеч - гектардан уңыш белән генә кызыксыналар. Ә бит кайсыбер бодай, уңышны күбрәк бирсә дә, җилемсәлелек буенча калышып, арзанрак хакка китәргә мөмкин. Һәм бу мәсьәләдә ачык мәгълүматлы булу өчен баш агрономнарга элеватор, иң элек аның лабораториясе белән тыгыз элемтәдә торырга кирәклеге турында тагын бер кабат искәртүнең зыяны юк.

Элеватор белән тыгыз элемтәдә тору дигәндә, тагын бер мөһим момент күздән ычкына әле. Сүз - ашлык йөкләренең хуҗалыклардагы һәм элеваторда үлчәнгән авырлыклары арасында аерманың зур булуы турында. Ул саннарга күз салсаң, билләһи, чәчләрең үрә торырлык. Булмаса да булмас икән быел икмәккә сан! Югыйсә, район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе куйган махсус дежурлар элеваторның үлчәү хуҗалыгында һәр машинаның авырлыгының хуҗалыкларда язып (үлчәп!) җибәрелгәне һәм мондагысы белән чагыштырып язып та бара инде. Әмма, кызганычка каршы, көн туса бер үк хәл кабатлана. Әйтик, 13 августта үлчәүдән үткән 80 машина йөкнең фәкать икесенең авырлыгы хуҗалыктагы белән туры килгән. Утыз машинаның йөге урындагыдан авыррак, 43енеке җиңелрәк чыккан. Әле бит аерма да 10 -15 килограмм гына булса, анысын машина яккан ягулык киму исәбенә генә чигерер идең, юк бит, кайсы йөкләр 3 - 4, хәтта 7 - 8 центнерга, кайчагында тонналап артык яки ким чыга. Әйтик, шул бер көнне генә дә «Рассвет»ның бер йөк ашлыгының авырлыгы төкмә -төк булса да, калганнары җәмгысы тонна ярымга ким чыккан. «Татарстан»ның өч машинасындагы ашлык 2 - 3 әр центнерга ким, дүртенчесендә, киресенчә, 1 тоннага якын артык булып чыга. Шул ук «Татарстан»нан 16 августта ташылган йөкләрне санап карасаң, хәл тагын да искитмәле:барлыгы 4 тонна чамасы ашлык ким чыга. Һәм мондый мисалларны барлык хуҗалыклардан да китерергә мөмкин булуы борчый. Шунысы кызганыч, күпчелек хуҗалыклардан мондый җитмәүчелек һәм артыклык көн саен кабатланып тора, «40 лет Победы», «Чирмешән», «Комбайн» һәм кайбер башка хуҗалыклардан исә һәр рейста аерма чыга. Әле менә 24ендә генә «Чирмешән»нән килгән ашлык 1 тонна 3 центнерга кимрәк чыккан...

Билгеле, ашлык аз чыкса да, күбрәк тартса да авырлыгы барыбер хуҗалыкка төшә, элеваторга моның бер генә дә зыяны юк. Шуңа күрә бу мәсьәлә, беренче чиратта, хуҗалыклардагы җитәкчеләрне һәм белгечләрне борчырга тиеш. Кызганычка каршы, күп урыннарда бу мәсьәләгә бармак аша гына карыйлар. Шулай булмаганда, көн туса никадәр ашлыкның кәгазьгә кереп тә чынлыкта юкка чыгуы уйландырырлык бит. Күпчелек хуҗалыкларда быелгы урак алдыннан үлчәүләр тикшертелмәгән, шуңа күрә кайбер хуҗалыкларның ике бригадасындагы үлчәүләрнең төрлечә күрсәтүен нәрсә белән аңлатасың. Мондый хәлгә «Киекле» хуҗалыгында тап булдык. Башка хуҗалыкларның да төрле бригадаларыннан килгән ашлыкның авырлыгында аермалар төрлечә, кайчагында капма - каршы булуы да шул хакта сөйли.

Еш кына очракларда ашлык бөтенләй дә үлчәмичә озатыла тагын.

Быел ашлыкның гомер булмаганча мулдан җыелуы аның төгәл исәбен алып бару дигән мәсьәләдә тезгенне йомшартты төсле. Әмма кадерледән кадерле икмәккә шулай сан булмавын кем генә гафу итәр икән.

**Н.ФОМИН,**
**авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү һәм сыйфат буенча баш дәүләт инспекторы.**

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**
**безнең корреспондент.**

# Берьюлы ике куян

## Каникул артта калды

Элек җәй көнне фәлән кадәр пионер лагере эшли иде дисәк тә, аларда быел район лагерьларында ял иткән кадәр булмый иде балалар. Бүгенге катлаулы, акчасызлык җилеккә үткән заманда да укучы балаларның ялын шулай нәтиҗәле итеп үткәрү мөмкинлеге табылгач, бик әйбәт инде ул. Әле бит ялы нинди! Берьюлы ике куянны ата торганы. Ял итү өчен дә, кызыксыну буенча да. Әнә, район мәгариф бүлеге каршындагы «Яшүсмер» профиль лагеренда ял иткән 420 бала арасында кемнәр генә юк иде?! Футбол сөючеләр, мәсәлән, агым буе спортның бу төре белән ныклап торып шөгыльләнеп кенә калмадылар, төрле шәһәрләрдә ярышларда да катнаштылар. Җиңел атлетика, чаңгы сөючеләр өчен аерым бер агым булды. Тегәргә, бәйләргә яратучылар, йөзләгән сәхнә сөюче балалар, мәктәп тормышы активистлары өчен махсус оештырылган агымда да ял итүчеләр аз булмады. Походлар, музейларга экскурсияләр, тарихи Болгар җирендә булу - балалар күңеленнән озак җуелмаслык истәлекләр. Ятимнәр, аз тәэмин ителешле гаиләләрдән булган балалар өчен оештырылган агымда ял итүчеләрнең дә сөенечләре эчләренә сыймады.

Гомумән, җәйге ялның төрләре, формалары күп булды быел. 2.352 бала мәсәлән, мәктәпләр каршында оештырылган ял һәм хезмәт лагерьларында үткәрделәр җәйләрен. Шәһәрнең беренче һәм дүртенче мәктәпләрендә көннәр аеруча нәтиҗәле узды. Икенчесендә йөрүчеләр тулы көннәрен мәктәп лагеренда үткәреп, НГДУ профилакториясенә йөреп дәваланырга да вакыт таптылар.

Шунысы куанычлы, соңгы елларда авыл мәктәпләре дә балалар ялының бу төрен теләп оештыралар. Кизләү, Биляр Озеро, Киекле, Егоркино мәктәпләрендә укучылар өчен, мәсәлән, быел база хуҗалары ярдәме белән тукландыру да оештырылды, кулларыннан килгән эш белән дә тәэмин ителде алар.

Районда хезмәт лагерьлары кебек җәйге ял формалары да популярлаша бара. Бу бик кулай форма. Мәктәп һәм хезмәт һәм мәшгульлек бюросы нигезендә төзелгән ике яклы килешү нигезендә балалар күмәкләшеп аерым бер төр эш белән шөгыльләнеп кенә калмыйча, башкарылган хезмәт өчен акча да ала алдылар. Яңа Әмзә мәктәбендә бу алым икенче ел кулланыла инде. Егоркино, Салдакай, 4 нче мәктәп (быел ике арада 18 килешү төзелде) һ.б.- барлыгы 420 укучы җәйге чорда мәктәпләрне ремонтлауда катнашып, мәктәп яны участокларында эшләп, хуҗалыкларга булышып,хәләл акчаларын эшләп алдылар.

НУРБ профилакториенда да, һәрвакыттагыча балалар ялы әйбәт оештырылды. «Заречный» лагере бераз соңрак ачылса да, балаларга ике сменада рәхәтләнеп ял итү өчен шартлар начар түгел иде.

Болардан тыш, район мәктәпләренең иң актив балалары республика лагеренда ял итү бәхетенә ирештеләр. Шуларның җидесе, ә алар төрле конкурсларда җиңүчеләр, «Мирас» лагеренда булып кайттылар. Тулаем республикадан җыелган балалар арасында да үзенең активлыгын, эзләнүчәнлеген күрсәткән Алсу Әхмәтҗанова (4 нче мәктәп) киләсе елда да «Мирас»та ял итүгә чакыру алган.

«Орбиталь», «Эколог» республика лагерьларында ял иткән укучыларыбыз да шулай республикабызның төрле төбәкләреннән җыелган балалар белән бергә ял итү, аралашудан канәгать калдылар.

Гомумән, балаларның җәйге ялы нәтиҗәле үтте дип авыз тутырып әйтерлек булды быел.

**Р.ГИНЯЕВА.**




## Туй шул ул...



Марсель һәм Ләйсән Кәлимуллиннарның «Норлат» шәһәр кунакханәсе ресторанында үткәргән туйлары озакка истә калырдыр. Залдагы заманча интерьер, купшы бизәлгән өстәлләр, яхшы хезмәт күрсәтү, баян моңы һәммәсе яшь парның һәм алар туендагы кунакларның кәефен күтәрерлек иде. Марсель яңа гына хәрби хезмәттән кайткан, ә Ләйсән Норлатка Яр Чаллыда сатучы булып эшләп килгән. Биш ел элек танышкан булганнар инде алар, очрашып, ә Марсель армиядә чакта хатлар алышып торганнар.

Ә туй чыннан да менә дигән булып үтте. Кунакханә рестораныңа гаилә бәйрәмнәре үткәрүгә яңадан-яңа заявкалар килә тора.

## Котлыйбыз!



1 сентябрьдә кызыбыз
**Эльмира Мөнир кызы Нәбиуллинага**
18 яшь тула.

Мул һәм олы бәхет килсен сиңа
Күтәренке булсын күңелең.
Шатлык, куанычлар белән генә
Үтсен иде синең гомерең.

**Иң изге теләкләр белән зур әтиең, зур әниең, әтиең, әниең, апаң һәм сеңелең.**

## Төрлесеннән

**Яшь гаилә фатир эзли (шикәрчеләр поселогында булса әйбәт). Завод ур., 10 - 7 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 2 - 13 - 89.**

***

**20 нче августта Биләр чишмәсе янында югалган Әхмәтҗанов Фәйзерахман исеменә бирелгән паспорт һәм пенсия кенәгәсен бүләк бәрабәренә Яңа Әмзә авылына яки Кормыш поселогы, Восточная ур., 11 адресы буенча китерүегезне үтенәбез.**

***

**Сираҗев Фәрит Нәҗип улы исеменә бирелгән шофер таныклыгын һәм тех. паспортны бүләк бәрабәренә Киекле авылына китереп бирүегезне сорыйбыз.**

## Белдерүләр



### Сатабыз

**Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир. Тел.: 5 - 29 - 57.**

***

**1982 елда чыккан, әйбәт хәлдәге «Москвич - 2140». Тел.: 5 - 11 - 99.**

***

**1995 елда чыккан ВАЗ - 21061. Тел.: 5 - 17 - 09 (кичке 5тән соң).**

***

**1993 елда чыккан, ак төстәге, 11 мең км. юл үткән ВАЗ - 21063. Тел.: 5 - 28 - 07.**

***

**1992 елда чыккан «Муравей» мотороллеры. Адрес: 60 лет Октября ур., 7 - 7 (кичке 5тән соң).**

***

**Чаналы гараж. Адрес: Карл Маркс ур., 1 - 19.**

***

**Красин урамындагы 10нчы йорт. Теләсә кайсы вакытта мөрәҗәгать итәргә.**

***

**Зур булмаган «Иней» суыткычы, кер юу машинасы, балалар караваты, йомшак җиһазлар. Кыйммәт түгел. Тел.: 2 - 27 - 86.**

***

**Килешү бәясенә печән (5 машина). Тәрнәс авылында Антипкин Сергейга мөрәҗәгать итәргә.**

***

**Каралты - куралары белән йорт. Адрес: Дружба ур., 22 - 1.**

***

**1984 елда чыккан ВАЗ - 21063. Каравыл Тавы авылында Борисов В.И.га мөрәҗәгать итәргә.**

***

**«Юпитер - 5», «Планета - 5» мотоцикллары. Тел.: 2 - 26 - 99.**

### Алмаштырабыз

**Яр Чаллы шәһәрендәге 2 бүлмәле фатир Норлаттагы шуңа тиң фатирга. Мичурин ур., 19 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.**

***

**Карл Маркс проспекты, 9 - 8 адресы буенча өч бүлмәле фатир ике һәм бер бүлмәлегә яки аз гаиләлеләр өчен бер бүлмәле фатир тибындагы, яки өстәмә түләп ике бүлмәлегә. К. Маркс проспекты, 9 - 7 (8) адресы буенча мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 4 - 16 - 35 (Әлмәт районы).**

### Ярминкәгә чакырабыз

**2 нче сентябрьдә иртәнге сәгать 8дән алып район мәдәният йортында Ульяновск күн комбинаты аяк киемнәре сәүдә ярминкәсе була. Киң ассортиментта: ир - атлар, хатын - кызлар, балалар, мәктәп өчен аяк киемнәре һәм галантерия товарлары.**

### Шифалы дарулар

***Сәдәфле мумие, гранулада женьшень, ак чыршы һәм шалкан майлары.***

**ЖЕНЬШЕНЬ - нервлар какшаганда ярдәм итә, йөрәк неврозын, баш авыртуларын дәвалый.**

**МУМИЕ - ашказанында шеш, бавырны, бөерне, сидек куыгында чир булганда файдаланыла.**

**АЛИСАТ (патша сәдәфләре) - югары кан басымын төшерә.**

**АНКИР - шикәр авыруы белән интегүчеләрнең гәүдә авырлыгын киметә, шулай ук организмнан шлаклар һәм зарарлы матдәләрне чыгара.**

**Магнит билбаулары, беләзекләр, олтыраклар бар. Сез бу шифалы даруларны 1 , 2 сентябрь көнне иртәнге сәгать 9дан 1гә кадәр район үзәк шифаханәсенең поликлиникасында сатып ала аласыз. Барлык препаратлар да сертификатка ия. Лицензия номеры - 000458.**

**Колбай Мораса урта мәктәбе коллективы әнисе Сафия Сәлимгәрәеваның вафат булуы сәбәпле укытучы**
**КАМАЕВА ГӨЛНУР ИЛДУС кызының тирән кайгысын уртаклаша.**


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2334 данә. Заказ № 8344.